ГЛАВА МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.09.2025 Мөслим № 38

**Муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында белешмәләрне Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына җибәрү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек турында килешүгә өстәмә килешү рәвешен раслау хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 43 статьясы, «Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 3 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләр башлыкларына муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында белешмәләрне әлеге карарга кушымта итеп бирелә торган форма нигезендә Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына җибәрү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек турында килешүгә өстәмә килешү төзергә тәкъдим итәргә.
2. Әлеге карарны рәсми рәвештә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә http://pravo.tatarstan.ru.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Муниципаль район Башлыгы А.Р. Хуҗин

Татарстан Республикасы муниципаль районы Башлыгының карарына кушымта
«______» ______________ 20________ел

**Муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында белешмәләрне Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына җибәрү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек турында килешү**

« » 20 ел.

Татарстан Республикасы муниципаль районы Уставы нигезендә эш итүче ______ Татарстан Республикасы муниципаль районы башлыгы (алга таба «район башлыгы» дип аталучы фамилиясе, исеме һәм атасының исеме күрсәтелә), бер яктан, һәм Татарстан Республикасы муниципаль районының ______ авыл җирлеге башлыгы (Татарстан Республикасы муниципаль районы Уставы нигезендә эш итүче фамилиясе, исеме һәм атасының исеме күрсәтелә) икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталачак, «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (алга таба - 14-ТРЗ номерлы Закон), «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 3 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - 92-ТРЗ номерлы Закон) белән әлеге Килешүне төзеделәр:

Килешү предметы

1.1. Килешү предметы булып муниципаль норматив хокукый актларны җыю һәм җибәрү мәсьәләләре буенча район башлыгының һәм җирлек башлыгының үзара эшчәнлеген оештыру һәм алар турында 14-ТРЗ номерлы Законның 5 статьясында (алга таба шулай ук - документлар) билгеләнгән белешмәләрне Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына (алга таба шулай ук - регистр) 92-ТРЗ номерлы Законны гамәлгә ашыру максатларында тапшыру тора.

2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Район башлыгы җирлек башлыгыннан документлар кабул итүне һәм аларны 14-ТРЗ номерлы Законда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда регистрга җибәрүне тәэмин итә.

2.2. Җирлек башлыгы түбәндәгеләрне тәэмин итә:

документларны 14-ТРЗ номерлы законда билгеләнгән нормалар һәм таләпләр нигезендә рәсмиләштерү;

регистрга кертү өчен җибәрелә торган документларның тулылыгы һәм 14-ТРЗ номерлы законда билгеләнгән белешмәләрнең дөреслеге;

район башлыгы карары белән расланган Татарстан Республикасы _______ муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль район составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турындагы белешмәләрне җыю һәм җибәрү буенча үзара хезмәттәшлек регламенты нигезендә билгеләнгән җирле үзидарә органына (вазыйфаи затына) документларны тапшыру _____________ 2025 _______

3. Килешүнең гамәлдә булу вакыты

3.1. Әлеге килешү аңа кул куйган вакыттан гамәлгә керә һәм якларның үзара ризалыгы белән аны өзгән вакытка кадәр гамәлдә була.

4. Килешүне туктату нигезләре һәм тәртибе

4.1. Әлеге Килешү вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

якларның килешүе буенча,

якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта.

5. Якларның Җаваплылыгы

5.1 якларның килешү шартларын үтәмәве яки тиешенчә үтәмәве килешүне берьяклы өзү өчен нигез булып тора.

6. Йомгаклау нигезләмәләре

6.1. Килешүгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр якларның үзара ризалыгы белән кертелә һәм язма рәвештә өстәмә килешү белән рәсмиләштерелә. Өстәмә килешүләр әлеге килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

6.2. Килешү тигез юридик көчкә ия ике нөсхәдә, һәр як өчен берәр нөсхәдә төзелде.

## 7. Якларның Имзалары

Татарстан Республикасы
___________________
муниципаль районы
Башлыгы
___________________

Татарстан Республикасы
___________________
муниципаль районы
авыл җирлеге
Башлыгы
___________________